РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шекше авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

2018 елның 6 августы | №13

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советы тарафыннан 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 31 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба районы Шекше авыл җирлегендә физик затларның мөлкәт салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым Кодексының 32 нче бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 64 нче маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Саба районы Шекше авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 31 нче номерлы Шекше авыл җирлеге Советы карары белән расланган “Шекше авыл җирлегендә физик затларның мөлкәт салымы турында” карарына (Шекше авыл җирлеге Советының 2015 елның 10 нчы августында кабул ителгән №28, 2015 елның 7 октябрендә кабул ителгән №7 карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2 нче пункты 2 нче пунктчасы 2 нче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“торак йортларны, торак йортларның өлешләрен”

1.2. карарның 2 нче пункты 3 нче пунктчасы 2 нче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“фатирларны, фатирларның өлешләрен”.

2. Әлеге карарның гамәлен 2015 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ shikshi адресы буенча һәм авыл җирлегенең информацион стендларында бастырырга.

Шекше авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Хайртдинов